ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» июля 2023 ел № 171

«2023 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларнын һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын 10.01.2023 елның 01 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларнын һәм яшьләрнең ялын оештыру, аларның мәшгульлеген мәктәп һәм студентлар каникуллары чорында тәэмин итү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларнын һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру турында» 10.01.2023 елның 01 номерлы карарына беркетелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карар буенча финанслауны бюджетның тиешле бүлекләрендә каралган акчалар чикләрендә тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасынын хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.06.2023 елда барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Л.Ф. Нургаянов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2023 елның 10
гыйнварындагы 01 номерлы карары
белән расланды
(карар редакциясендә 21.06.2023 171)

**«2023 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 10.01.2023 елның 01 номерлы карарына үзгәрешләр**

«2023 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларнын һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын 10.01.2023 елнын 01 номерлы карарына үзгәрешләр:

1) Карарның 4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Әлеге категориядәге балалар төркемнәрен формалаштыру эшләрен башкару өчен җаваплы башкаручы итеп Әгерҗе муниципаль районының «Ровесник» яшүсмерләр клубы һәм Әгерҗе муниципаль районынын «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесен билгеләргә.».

2) 2023 елга Әгерҗе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнен ялын оештыру программасының 2 бүлегендәге 2 нче таблицаның 1 нче пунктын түбәндәге юл белән тулыландырырга:

| Т/с | Лагерь исеме | Күләме | Бюджеты | Ата-аналар кертемнәре | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Әгерҗе муниципаль районының "Ровесник" Яшүсмерләр клубы муниципаль бюджет учреждениесендә ТЖС балалары өчен шәһәр читендәге лагерь | 20 (18 көн) | 389 160,00 | - | 389 160,00 |

3) 2023 елга Әгерҗе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнен ялын оештыру программасынын 2 бүлегендәге 3 нче таблицаның 2 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Т/с | Лагерь исеме | Күләме | Бюджеты | Ата-аналар кертемнәре |
|---|---|---|---|---|
| 2 | ТЖС (МБУ ЦМ (С) ФООП Форпост) балалар өчен шәһәр читендәге лагерь | 40 (21 көн) | 972 940, 00 | - |
| | | 10 (7 көн) | 75 700,00 | - |